ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

**ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ исем.
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ һәм СӘНГАТЬ
ИНСТИТУТЫ**

420111, Казан, Лобачевский ур., 2/31

Тел (843) 292-76-59
Факс (843) 292-21-47

АКАДЕМИЯ НАУК
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**ИНСТИТУТ ЯЗЫКА,
ЛИТЕРАТУРЫ и ИСКУССТВА
им. ГАЛИМДЖАНА ИБРАГИМОВА**

420111, Казань, ул. Лобачевского, 2/31

Email: iyali.anrt@mail.ru, www.iyali.antat.ru

ИНН 1654008987 / кпп 165545002/ ОГРН 1021602836441/ ОКПО 27889993/ УФК по РТ / МФ РТ л/с ЛБГ 00730017-Ибраг АН / Институт языка литературы и искусства им. Г.Ибрагимова АН РТ р/с 40601810192053000001
ГРКЦ НБ РТ Банка России БИК 049205001

13.02.2015г № 01-20/31
На № ______________ от ______________

Татарстан Республикасының
Милли китапханәсе директоры
С.Р. ЗИГАНШИНАГА

**Хөрмәтле Сөембикә Рәзилевна һәм
Татарстан Республикасы Милли китапханәсе хезмәткәрләре!**

Татарстан Фәннәр Академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты һәм шәхсән үз исемемнән Сезне Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең150-еллык юбилее белән ихлас күңелдән котлыйм.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе озын һәм вакыйгаларга бай юл үткән. Аның мәгърифәт һәм мәгариф, халкыбызның рухи һәм интеллектуаль үсешенә керткән өлеше – бәхәссез. Сез халыкны китап белән тәэмин итү, уникаль китапларны саклау, киләчәк буынга җиткерү, төрле телләрдә язылган язма истәлекләрне, кулъязмаларны җыю, тикшерү кебек әһәмиятле эшләр башкарасыз.

Китапханәнең милли һәм төбәкара библиөграфия үзәге буларак та роле һичшиксез мөһим. Бүгенге көндә Татарстан Республикасы Милли китапханәсе – республика китапханәләре өчен библиографик һәм методик үзәк, дөньяда татар әдәбиятын саклау һәм тарату белән шөгыльләнә торган бердәнбер ачык китапханә. Сезнең китапханә бик күп еллар дәвамында татар укучыларына хезмәт күрсәтүче чит ил китапханәләре белән элемтәдә тора. Россиянең күпләп татарлар яшәгән төбәкләренең, якын һәм ерак чит илләрнең китапханәләрен татар язучылары һәм шагыйрьләренең китаплары белән тәэмин итә.

Милли китапханә, бүгенге көн таләпләре югарылыгында, җәмгыять ихтыяҗларын канәгатьләндерә, эшлекле һәм иҗади элемтәләрне ныгыта. Китапханә Идел буе халыкларының тарихын өйрәнү, мәдәни бәгланышларны ныгыту юнәлешендә дә зур эш башкара.

Сезнең тарафтан «Татарстан Республикасының җыелма электрон китапханә каталогы» проекты тормышка ашырылып килә. Бу ресурс

китапханәләр фондларыннан барлык кирәкле мәгълүматны тиз арада табарга мөмкинлек бирә.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең миссиясе зур. Ул укучысын беркайчан да югалтмаячак, чөнки халкыбызның бай рухи һәммәдәни традицияләренә таянып яши, сайлаган кыйбласыннан тайпылмый.

Юбилей уңаеннан китапханәгезгә иҗади уңышлар, яңа идеяләрнең тормышка ашуын, хезмәткәрләрегезгә сәламәтлек, иминлек телим.

**Директор, Татарстан Фәннәр Академиясенең мөхбир әгъзасы, профессор** **К.М.Миңнуллин**